СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Габделхая Каримова, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**Карары**

**03 март 2025ел.** **№153**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының “Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә хәрби исәп буенча белгечләргә хезмәт өчен түләү турындагы нигезләмәне раслау турында” 2024 елның 10 декабрендәге 148 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

РФ Хөкүмәтенең “Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында” 2006 елның 29 апрелендәге 258 номерлы карары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 144 статьясы, Россия Федерациясе Оборона министрының “Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрби частьләре һәм оешмалары гражданлык персоналына (хезмәткәрләренә) хезмәт өчен түләү системасы турында” 2024 елның 29 сентябрендәге 595 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының “Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә хәрби исәп буенча белгечләргә хезмәт өчен түләү турындагы нигезләмәне раслау турында” 2024 елның 10 декабрендәге 148 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада “РФ оборона министрының “Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби частьлары һәм оешмалары гражданлык персоналының (хезмәткәрләренең) хезмәтенә түләү системасы турында” 2019 елның 18 сентябрендәге 545 номерлы боерыгы белән» дигән сүзләрне “РФ оборона министрының “Россия Федерациясе Хәрби Көчләре хәрби частьләре һәм оешмаларының гражданлык персоналының (хезмәткәрләренең) хезмәтенә түләү

системасы турында” 2024 елның 30 сентябрендәге 595 номерлы боерыгы белән” дип үзгәртергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы** **В.В.Сәгыйтов**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1121690000210 * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609012678